КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 24 май г.Казань № 362

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 282 нче; 2013 ел, 29 апрель, 294 нче; 2013 ел, 29 июнь, 454 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 24 октябрь, 789 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1110 нчы; 2014 ел, 15 март, 157 нче; 2014 ел, 14 апрель, 242 нче; 2014 ел, 11 июнь, 405 нче; 2014 ел, 9 июль, 475 нче; 2015 ел, 6 май, 326 нчы; 2015 ел, 16 май, 346 нчы; 2015 ел, 22 июль, 532 нче; 2016 ел, 17 февраль, 101 нче; 2016 ел, 27 апрель, 252 нче; 2016 ел, 12 май, 298 нче; 2016 ел, 10 июнь, 396 нчы; 2016 ел, 12 октябрь, 740 нчы; 2016 ел, 26 декабрь, 989 нчы; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 13 май, 281 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 821 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 895 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1117 нче; 2018 ел, 11 июнь, 458 нче; 2018 ел, 16 ноябрь, 1002 нче; 2019 ел, 5 март, 156 нчы; 2019 ел, 26 апрель, 344 нче; 2019 ел, 27 июнь, 517 нче; 2019 ел, 13 сентябрь, 830 нчы; 2019 ел, 11 декабрь, 1136 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә, 25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «25. | Татарстан Республикасында энергия ресурс- | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, | Тормыш сыйфатын, чыгарыла торган продукциянең конкуренциягә сәләтен өзлексез арттыр- |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | лары нәтиҗәле-леге | сәүдә мини-стрлыгы | Татарстан Рес-публикасының җирле үзидарә органнары (киле-шү буенча), Та-тарстан Респуб-ликасы предприя-тиеләре, оешма-лары һәм учреж-дениеләре (киле-шү буенча) | ган рәвештә Татарстан Республикасында энер-гияне саклау белән идарә итүнең нәтиҗәле сис-темасын формалаштыру һәм энергетика нәтиҗә-лелеген күтәрү.<br>Транспорт һәм финанс чыгымнарын киметү һәм транспортның әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын азайту өчен традицион ягулык төрлә-рендә эшли торган төрле транспортны һәм җиһаз-ны сыекландырылган та-бигый газда эшли торган транспорт һәм җиһаз белән этаплап алмаш-тыру». |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 4 декабрь, 954 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 13 май, 317 нче; 2014 ел, 24 сентябрь, 670 нче; 2014 ел, 12 ноябрь, 861 нче; 2015 ел, 26 март, 189 нчы; 2016 ел, 2 декабрь, 889 нчы; 2018 ел, 28 май, 404 нче; 2018 ел, 10 сентябрь, 765 нче; 2019 ел, 22 гыйнвар, 32 нче; 2019 ел, 30 октябрь, 971 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» сүзләрен «Татарстан Республикасында энергия ресурслары нәтиҗәлелеге» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» сүзләрен «Татарстан Республикасында энергия ресурслары нәтиҗәлелеге» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Россия Федерациясе Энергетика министрлыгы» сүзләреннән соң «һәм Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин